**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2024 Балык Бистәсе штп. №209пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларын раслау һәм юкка чыгару турында" 28.05.2021 ел, №111пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында»29.12.2022 №612-ФЗ, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»29.12.2023 №608-ФЗ Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектын төзү проектын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 3 - 7 өлешләрендә каралган чараларны башкару өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм кирәкле төзүчегә, техник заказчыга каралган документларның, белешмәләрнең, материалларның тулы исемлеген раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 25.12.2021 ел, №2490" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 11.02.2022 №28пи карарына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.05.2021 №111пи карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (27.06.2022 №133пи, 14.02.2023 №27пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5.1 пунктының 7 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.05.2021 №111пи карары белән расланган күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа биналар булдырудан, шул исәптән Торак кодексының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бинаның (урыннарның) чикләре һәм (яисә) мәйданы турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм барлыкка килгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу кирәклегенә китерә;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов